МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

07.11.2022 Казан ш № 988

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәмен бирү (күрсәтү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 22 сентябрендәге 670 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәмен бирү (күрсәтү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәмен бирү (күрсәтү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 22 сентябрендәге 670 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 19.07.2016 №412, 08.06.2017 №348, 25.01.2018 №60, 07.05.2018 № 348, 18.09.2018 №885, 02.07.2019 №509, 14.11.2019 №1016,

07.02.2020 №80, 01.09.2020 №605, 22.12.2020 №885, 02.06.2021 №385, 06.08.2021 №564, 01.10.2021 №709, 30.05.2022 №437 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәмен бирү (күрсәтү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.11.2022 ел. № 988 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәмен бирү (күрсәтү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 22 сентябрендәге 670 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәмен бирү (күрсәтү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2.1. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында социаль яклау идарәсе (бүлеге) аша (алга таба – Идарә (бүлек), Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны яки тору урыны буенча гамәлгә ашырыла.»;

2.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Дәүләт хезмәте, әгәр:

социаль контракт төземичә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән тапшырылган булса, гариза һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып ун көн эчендә күрсәтелә.

эш эзләү, шәхси эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру («Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланганда һөнәри керемгә салым түләүче сыйфатында теркәлү), шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару буенча чараларны гамәлгә ашыруга социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән тапшырылса, гаризаны һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып 23 көн эчендә күрсәтелә.

гражданин тарафыннан авыр тормыш хәлен җиңеп чыгу буенча чараларны тормышка ашыру өчен социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү турында гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән тапшырылса, әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән башлап 30 көн эчендә күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте, әгәр:

социаль контракт төземичә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан почта аша юллап тапшырылган булса, Идарә (бүлек) тарафыннан гариза һәм әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып 10 көн эчендә күрсәтелә.

социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан почта аша юллап тапшырылган булса, Идарә )бүлек тарафыннан гариза һәм әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып 30 көн эчендә күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте, әгәр:

социаль контракт төземичә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинет аша бирелгән очракта, Идарә (бүлек) тарафыннан дәүләт хезмәте гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә номер һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетта чагылдырыла торган «Документлар тикшерү» статусы бирелгән көннән башлап 10 эш көне эчендә күрсәтелә.»;

социаль контракт нигезендә социаль ярдәм күрсәтү турында гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинет аша бирелгән очракта, Идарә (бүлек) тарафыннан гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә номер һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетта чагылдырыла торган «Документлар тикшерү» статусы бирелгән көннән башлап 10 эш көне эчендә күрсәтелә.»;

2.6.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«2.6.1. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән тапшырыла торган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар:

мөрәҗәгать итүченең гаилә һәм матди-көнкүреш хәле турында гариза һәм анкета:

әлеге Регламентка 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә кәгазь документ формасында;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы һәм Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткәндә, электрон формада (Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында һәм Бердәм порталда, гаризаны нинди дә булса башка төрле формада өстәмә тапшыру зарурлыгыннан башка гына) интерактив форманы тутыру юлы белән), әлеге пункт таләпләре нигезендә имзалап;

керемнәрне раслый торган документлар (мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының керемнәре булган очракта);

белем алу турында документ (мөрәҗәгать итүче яки аның гаилә әгъзалары белем алган очракта);

чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә күчермәсе;

өйләнешүне (аерылышуны) дәүләт теркәвенә алу турында чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә күчермәсе;

хәрби оешмаларда уку турында документ (мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзаларын укыган очракта);

сак астына алу турында суд карары (гаилә әгъзасын сак астына алган очракта);

мәҗбүри дәвалау турында суд карары (гаилә әгъзасы мәҗбүри дәвалануда булганда);

туганлык мөнәсәбәтләрен раслый торган суд карары (туганлык мөнәсәбәтләре судта расланган очракта);

тулы дәүләт тәэминатында булу турында документ (мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзасын мәҗбүри дәвалауда булган очракта).

Янгын, су басу яисә башка табигый бәла-казалар нәтиҗәсендә авыр тормыш хәленә бәйле рәвештә дәүләт социаль ярдәмен алу өчен мөрәҗәгать иткән очракта, өстәмә рәвештә хәлләрнең килеп чыгуын раслаучы документлар (актның күчермәләре, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы бүлекчәсеннән булган факт турында белешмә) тапшырыла.

Шәхси эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару буенча чараларны тормышка ашыру өчен социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү өчен мөрәҗәгать итү очрагында бизнес-план тәкъдим ителә.

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать иткәндә, үзләренең шәхесен таныклый торган һәм мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итү вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.

Гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүченең яки аның законлы вәкиленең шәхесен таныклаучы документтан белешмәләр Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм системасындагы (алга таба – БИАС) исәпкә алу язуын раслаганда тикшерелә.

Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган, юридик зат тарафыннан бирелгән документ документны биргән вәкаләтле затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган булырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган, шәхси эшкуар тарафыннан бирелгән документ шәхси эшкуарның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган булырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган, нотариус тарафыннан бирелгән документ нотариусның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган булырга тиеш. Башка очракларда – гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш.»;

2.6.2 пунктның сигезенче абзацына «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре).» сүзләрен өстәргә;

2.6.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.4. Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша түбәндәге мәгълүматлар алына:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен раслаучы документ (иске паспортлар белән паспорт досьесы) дөреслеген раслый торган документ (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан);

яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәлү исәбе турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан);

вәкаләтле оешмалардан – мөрәҗәгать итүче белән аның даими яшәү урыны (тору урыны) буенча теркәлгән гражданнар турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан);

индивидуаль шәхси счетның иминият номеры турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан ) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәл була);

индивидуаль шәхси счетның иминият номеры турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан ) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәл була);

эшсез сыйфатында теркәлү, эшсезлек буенча пособие (стипендия һәм бүтән түләүләр) алу һәм аның күләме турында (халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте органнарыннан);

Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды тарафыннан гамәлгә ашырыла торган пенсияләр, компенсация түләүләре алу һәм пенсионерларны өстәмә айлык матди тәэмин итү турында (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була) (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

хәрби хезмәткәрләргә түләнә торган пенсия күләме турында (Россия Федерациясе Оборона министрлыгыннан);

йөклелек һәм бала тудыру буенча Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды тарафыннан түләнә торган пособие күләмнәре турында (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була) (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

вакытлыча эшкә сәләтсезлек буенча пособие күләме турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан ) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәл була);

йөклелекнең башлангыч чорларында медицина оешмаларында исәпкә баскан хатын-кызларга бер тапкыр бирелә торган пособие күләме турында (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була) (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

бала карау буенча ай саен Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды тарафыннан түләнә торган пособие күләмнәре турында (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була) (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган айлык иминият түләүләре турында, әгәр медик-социаль экспертиза учреждениесе

бәяләмәсе буенча иминият очрагы барлыкка килүенең нәтиҗәсе булып аның профессиональ эшкә сәләтен югалтуы торса, яисә аларны алу хокукына ия булган затларга, – әгәр иминият очрагы барлыкка килүенең нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның вафаты торса (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

әлеге пунктчада күрсәтелгән, социаль яклау органнары тарафыннан түләнә торган барлык социаль түләү төрләренә өстәмәләр һәм өстәмә түләүләр күләме турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

социаль яклау органнары тарафыннан түләнә торган Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән башка социаль түләүләр күләмнәре турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

баланың тууын дәүләт теркәве турында (Федераль салым хезмәтеннән);

гаилә коруны дәүләт теркәве турында (Федераль салым хезмәтеннән);

аерылышуны дәүләт теркәве турында (Федераль салым хезмәтеннән);

опека (попечительлек) билгеләү һәм опекунның (попечительнең) бала асрауга акча алуы турында («Опека һәм попечительлек» автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан);

баланы тәрбиягә бала алучы гаиләгә тапшыру һәм тәрбиягә бала алучы ата-аналарга тиешле түләүнең суммалары турында («Опека һәм попечительлек» автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан);

ата-ана хокукыннан мәхрүм итү яки ата-ана хокукларын чикләү турында («Опека һәм попечительлек» автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан);

мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының күчемсез мөлкәте турында Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында булган белешмәләр (Росреестрдан);

билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урыны турында (Росреестрдан);

мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының транспорт чаралары булуы турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан);

хезмәт һәм башка бурычларны үтәгән өчен түләү, шул исәптән кызыксындыру характерындагы түләүләр, башкарылган эш, күрсәтелгән хезмәт өчен бүләкләү, гражданлык хокукы килешүе кысаларында гамәлләр кылган өчен бүләкләү турында (Федераль салым хезмәтеннән);

дивидендлар, шулай ук кыйммәтле кәгазьләр белән операцияләр буенча алынган процентлар турында (Федераль салым хезмәтеннән);

эшкуарлык эшчәнлегеннән һәм шәхси практиканы гамәлгә ашырудан алынган керемнәр турында (Федераль салым хезмәтеннән);

авторлык заказы, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә аерым хокукны читләштерү турындагы килешүләр буенча алынган керемнәр турында (Федераль салым хезмәтеннән);

мөлкәтне сатудан, арендалаудан кергән табыш турында (Федераль салым хезмәтеннән);

ышанычнамә бирү факты һәм аның эчтәлеге турында (Федераль нотариаль палатасыннан);

18 яшькә кадәрге инвалид баланы яисә балачактан I төркем инвалидны яисә хезмәткә сәләтсез затларны караган затлар турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

мөрәҗәгать итүченең яки аның гаилә әгъзаларының иректән мәхрүм итү урыннан (урыннарыннан) чыгарылуы (тотылуы) турында (Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтеннән);

элегрәк алынган дәүләт социаль ярдәме турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәл була);

эш эзләү чараларын, гражданның авыр тормыш хәлен җиңү буенча башка чараларны гамәлгә ашыруга социаль контракт нигезендә элегрәк алынган дәүләт социаль ярдәме турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

социаль хезмәтләр җыелмасы рәвешендә дәүләт социаль ярдәме турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәл була);

үлем турында (Федераль салым хезмәтеннән);

фамилиясен, исемен, әтисенең исемен алыштыру турында (Федераль салым хезмәтеннән);

аталыкны билгеләү турында (Федераль салым хезмәтеннән);

фамилия-исем төркемнәренең, туу датасының, җенеснең һәм СНИЛС туры килүе турында (Федераль салым хезмәтеннән);

инвалидлык турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

опека билгеләү турында («Опека һәм попечительлек» автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан);

мөмкинлекләре чикләнгән затка попечитель билгеләү турында («Опека һәм попечительлек» автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан).

Мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның әлеге пунктында күрсәтелгән документларны (белешмәләрне) үз инициативасы буенча тапшырырга хокуклы.

Югарыда аталган белешмәләрне үз эченә алган әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора.»;

2.12.4 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Идарәнең (бүлекнең) хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

2.12.4 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) Идарә (бүлек) хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;»;

2.13.1 пунктның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Идарә (бүлек) хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә дәүләт хезмәте күрсәтүгә комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтелүе.»;

3 бүлектә:

3.3.1 пунктның унҗиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гарызнамәгә формат-мантыйкый тикшерү Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә, гарызнамәдә электрон форманың һәр кырын мөрәҗәгать итүче тарафыннан тутыру барышында орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла. Бердәм порталда мөрәҗәгатьнең электрон формасындагы кырлар төгәлсезлекләр белән тутырылган булуы ачыкланган очракта, турыдан-туры мөрәҗәгатьнең электрон формасында мәгълүмат җиткерү юлы белән, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.»;

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Мәгълүматлар алу, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр төзү һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү

3.4.1. Идарә (бүлек) белгече электрон рәвештә түбәндәге белешмәләрне ала:

вәкаләтле оешмалардан – мөрәҗәгать итүче белән аның даими яшәү урыны (тору урыны) буенча теркәлгән гражданнар турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан);

индивидуаль шәхси счетның иминият номеры турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәл була);

эшсез сыйфатында теркәлү, эшсезлек буенча пособие (стипендия һәм бүтән түләүләр) алу һәм аның күләме турында (халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте органнарыннан);

түбәндәгеләрне алу һәм аларның күләмнәре турында: Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды тарафыннан гамәлгә ашырыла торган пенсияләр, компенсация түләүләре алу һәм пенсионерларны өстәмә айлык матди тәэмин итү турында (хезмәткә сәләтсез гражданнарны тәрбияләүче эшләмәүче хезмәткә сәләтле затларга компенсация түләүләреннән тыш) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була) (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

хәрби хезмәткәрләргә түләнә торган пенсия күләме турында (Россия Федерациясе Оборона министрлыгыннан);

пенсияне алу, билгеләү, алмау һәм түләүләрне туктату турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

йөклелек һәм бала тудыру буенча Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды тарафыннан түләнә торган пособие күләмнәре турында (әлеге

абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була) (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

вакытлыча эшкә сәләтсезлек буенча пособие күләме турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәл була);

йөклелекнең башлангыч чорларында медицина оешмаларында исәпкә баскан хатын-кызларга Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан бер тапкыр бирелә торган пособие күләме турында (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була) (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

бала карау буенча ай саен Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды тарафыннан түләнә торган пособие күләмнәре турында (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була) (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган айлык иминият түләүләре турында, әгәр медик-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып аның профессиональ эшкә сәләтен югалтуы торса, яисә аларны алу хокукына ия булган затларга, – әгәр иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның вафаты торса (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

әлеге пунктчада күрсәтелгән, социаль яклау органнары тарафыннан түләнә торган барлык социаль түләү төрләренә өстәмәләр һәм өстәмә түләүләр күләме турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

социаль яклау органнары тарафыннан түләнә торган Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән башка социаль түләүләр күләмнәре турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

баланың тууын дәүләт теркәве турында (Федераль салым хезмәтеннән);

гаилә коруны дәүләт теркәве турында (Федераль салым хезмәтеннән);

аерылышуны дәүләт теркәве турында (Федераль салым хезмәтеннән);

опека (попечительлек) билгеләү һәм опекунның (попечительнең) бала асрауга акча алуы турында («Опека һәм попечительлек» автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан);

баланы тәрбиягә бала алучы гаиләгә тапшыру һәм тәрбиягә бала алучы ата-аналарга тиешле түләүнең суммалары турында («Опека һәм попечительлек» автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан);

мөрәҗәгать итүчене ата-ана хокукыннан мәхрүм итү яки ата-ана хокукларын чикләү турында («Опека һәм попечительлек» автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан);

мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының күчемсез мөлкәте турында Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында булган белешмәләр (Росреестрдан);

билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урыны турында (Росреестрдан);

мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының транспорт чаралары булуы турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан);

хезмәт һәм башка бурычларны үтәгән өчен түләү, шул исәптән кызыксындыру характерындагы түләүләр, башкарылган эш, күрсәтелгән хезмәт өчен бүләкләү, гражданлык хокукы килешүе кысаларында гамәлләр кылган өчен бүләкләү турында (Федераль салым хезмәтеннән);

дивидендлар, шулай ук кыйммәтле кәгазьләр белән операцияләр буенча алынган процентлар турында (Федераль салым хезмәтеннән);

эшкуарлык эшчәнлегеннән һәм шәхси практиканы гамәлгә ашырудан алынган керемнәр турында (Федераль салым хезмәтеннән);

авторлык заказы, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә аерым хокукны читләштерү турындагы килешүләр буенча алынган керемнәр турында (Федераль салым хезмәтеннән);

мөлкәтне сатудан, арендалаудан кергән табыш турында (Федераль салым хезмәтеннән). Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

3.4.2. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга (оешмаларга) җибәрү.

3.4.2.1. Мөрәҗәгать итүченең теркәлгән гаризасы рәсми мөрәҗәгать җибәрү өчен нигез булып тора.

3.4.2.2. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат Регламентның 2.6.4 пунктында каралган документларны һәм белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр әзерли һәм җибәрә (шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып).

3.4.2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, сорала торган документлар исемлеге:

1) мөрәҗәгать итүченең шәхесен раслаучы документның дөреслеген раслый торган (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан);

2) яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәлү исәбе турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан);

3) вәкаләтле оешмалардан – мөрәҗәгать итүче белән аның даими яшәү урыны (тору урыны) буенча теркәлгән гражданнар турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан);

4) индивидуаль шәхси счетның иминият номеры турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан ) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәл була);

5) индивидуаль шәхси счетның иминият номеры турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан ) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәл була);

6) эшсез сыйфатында теркәлү, эшсезлек буенча пособие (стипендия һәм бүтән түләүләр) алу һәм аның күләме турында (халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте органнарыннан);

7) түбәндәгеләрне алу һәм аларның күләмнәре турында: Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды тарафыннан гамәлгә ашырыла торган пенсияләр, компенсация түләүләре алу һәм пенсионерларны өстәмә айлык матди тәэмин итү турында (хезмәткә сәләтсез гражданнарны тәрбияләүче эшләмәүче хезмәткә сәләтле затларга компенсация түләүләреннән тыш) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була) (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

8) хәрби хезмәткәрләргә түләнә торган пенсия күләме турында (Россия Федерациясе Оборона министрлыгыннан);

9) пенсияне алу, билгеләү, алмау һәм түләүләрне туктату турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

10) йөклелек һәм бала тудыру буенча Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды тарафыннан түләнә торган пособие күләмнәре турында (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була) (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

11) вакытлыча эшкә сәләтсезлек буенча пособие күләме турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәл була);

12) йөклелекнең башлангыч чорларында медицина оешмаларында исәпкә баскан хатын-кызларга Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан бер тапкыр бирелә торган пособие күләме турында (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була) (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

13) бала карау буенча ай саен Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды тарафыннан түләнә торган пособие күләмнәре турында (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була) (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

14) җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган айлык иминият түләүләре турында, әгәр медик-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып аның профессиональ эшкә сәләтен югалтуы торса, яисә аларны алу хокукына ия булган затларга, – әгәр иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның вафаты торса (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

15) әлеге пунктчада күрсәтелгән, социаль яклау органнары тарафыннан түләнә торган барлык социаль түләү төрләренә өстәмәләр һәм өстәмә түләүләр күләме турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

16) социаль яклау органнары тарафыннан түләнә торган Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә

органнары тарафыннан билгеләнгән башка социаль түләүләр күләмнәре турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

17) баланың тууын дәүләт теркәве турында (Федераль салым хезмәтеннән);

18) гаилә коруны дәүләт теркәве турында (Федераль салым хезмәтеннән);

19) аерылышуны дәүләт теркәве турында (Федераль салым хезмәтеннән);

20) опека (попечительлек) билгеләү һәм опекунның (попечительнең) бала асрауга акча алуы турында («Опека һәм попечительлек» автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан);

21) баланы тәрбиягә бала алучы гаиләгә тапшыру һәм тәрбиягә бала алучы ата-аналарга тиешле түләүнең суммалары турында («Опека һәм попечительлек» автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан);

22) мөрәҗәгать итүчене ата-ана хокукыннан мәхрүм итү яки ата-ана хокукларын чикләү турында («Опека һәм попечительлек» автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан);

23) мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының күчемсез мөлкәте турында Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында булган белешмәләр (Росреестрдан);

24) билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урыны турында (Росреестрдан);

25) мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының транспорт чаралары булуы турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан);

26) хезмәт һәм башка бурычларны үтәгән өчен түләү, шул исәптән кызыксындыру характерындагы түләүләр, башкарылган эш, күрсәтелгән хезмәт өчен бүләкләү, гражданлык хокукы килешүе кысаларында гамәлләр кылган өчен бүләкләү турында (Федераль салым хезмәтеннән);

27) дивидендлар, шулай ук кыйммәтле кәгазьләр белән операцияләр буенча алынган процентлар турында (Федераль салым хезмәтеннән);

28) эшкуарлык эшчәнлегеннән һәм шәхси практиканы гамәлгә ашырудан алынган керемнәр турында (Федераль салым хезмәтеннән);

29) авторлык заказы, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә аерым хокукны читләштерү турындагы килешүләр буенча алынган керемнәр турында (Федераль салым хезмәтеннән);

30) мөлкәтне сатудан, арендалаудан кергән табыш турында (Федераль салым хезмәтеннән).

31) ышанычнамә бирү факты һәм аның эчтәлеге турында (Федераль нотариаль палатасыннан);

32) 18 яшькә кадәрге инвалид баланы яисә балачактан I төркем инвалидны яисә хезмәткә сәләтсез затларны караган затлар турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

33) мөрәҗәгать итүченең яки аның гаилә әгъзаларының иректән мәхрүм итү урыныннан (урыннарыннан) чыгарылуы (тотылуы) турында (Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтеннән);

34) элегрәк алынган дәүләт социаль ярдәме турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәл була);

35) үлем турында (Федераль салым хезмәтеннән);

36) фамилиясен, исемен, әтисенең исемен алыштыру турында (Федераль салым хезмәтеннән);

37) аталыкны билгеләү турында (Федераль салым хезмәтеннән);

38) фамилия-исем төркемнәренең, туу датасының, җенеснең һәм СНИЛС туры килүе турында (Федераль салым хезмәтеннән);

Әлеге органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гаризаны һәм гаризага теркәлгән документларны теркәгән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: электрон формада алынган мәгълүматлар, мәгълүмат бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.4.3. Әлеге Регламентның 2.6.4 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре, аларда булган белешмәләр) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

3.4.4. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

2) ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, Регламентның 2.6.4 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) әлеге документлар алар карамагында булган органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы федераль законның $7^2$ статьясындагы 3 өлеше нигезендә ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара рәсми мөрәҗәгать алынган көннән башлап биш эш көненнән (ике эш көне –дәүләт кадастр исәбен һәм (яисә) күчемсез мөлкәт объектларына хокукларны дәүләт теркәвенә алганда) артмаска тиеш.

Процедураның нәтиҗәсе булып сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки андагы белешмәләрне) алу яисә ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелгән баш тарту турында белдерүләр тора.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм

мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.».

3.6.3 пунктының беренче абзацын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.6.3. Идарә (бүлек) белгече Гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданинның) социаль адаптацияләү программасын һәм бизнес-планны карау һәм раслау өчен Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссиягә җибәрә.»;

3.6.4 пунктының беренче абзацын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.6.4. Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия Гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданинның) социаль адаптация программасын һәм бизнес-планны карый һәм раслый.»;

4.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Белешмә телефоннар, дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр Министрлыкның рәсми сайтында (http://mtsz.tatarstan.ru) урнаштырыла.»;

3.9 пунктның икенче кызыл юлын түбәндәгечә үзгәртеп бирергә:

«Идарә (бүлек) белгече мөрәҗәгать итүчегә кабул ителгән дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар турында гаризада күрсәтелгән ысул (хат, смс-хәбәр, электрон почта, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша) белән хәбәр итә.»;

Регламентка кушымтаны (белешмәлекне) үз көчен югалткан дип танырга.